| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

2018 елның 31 августы Баулы шәһәре № 80

“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге территориясендә үзбелдек
белән куелган, законсыз урнаштырылган
һәм төзелгән күчемле һәм күчемсез
милекне ачыклау һәм сүтү тәртибе турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы “Җирле үзидәрә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль Законга, Россия Федерациясе Граҗданнар кодексына ярашлы рәвештә Баулы шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә үзбелдек белән куелган, законсыз урнаштырылган һәм төзелгән күчемле һәм күчемсез милекне ачыклау һәм сүтү тәртибе турында нигезләмәне кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге башкарма комитетын Баулы шәһәре территориясендә үзбелдек белән куелган, законсыз урнаштырылган һәм төзелгән күчемле һәм күчемсез милекне ачыклау һәм сүтүгә вәкаләтле ораган буларак билгеләргә.

3. Әлеге карарны үтәүне тикшерүне Баулы шәһәре Советының икътисад үсеше, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе — Р.Х. Гатиятуллин

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Баулы шәһәре Советының
2018 елның 31 августында
кабул ителгән 80нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә үзбелдек белән куелган, законсыз урнаштырылган һәм төзелгән күчемле һәм күчемсез милекне ачыклау һәм сүтү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

**1.Гомуми положениеләр**

1.1 Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе җир кодексы һәм башка гамәлдәге норматив-хокукый актларга ярашлы рәвештә төзелде.

1.2 Әлеге Нигезләмә мәгълүматның ачыклыгы, шулай ук үзбелдек белән куелган, законсыз урнаштырылган һәм төзелгән күчемле һәм күчемсез милекне сүтү турындагы карарларның законлылыгы принципларына нигезләнгән һәм оештыру-хокук формасына һәм милекчелек формасына карамастан барлык гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан үтәлүе мәҗбүри.

1.3. Әлеге Нигезләмә үзбелдек белән Баулы шәһәре муниципаль милеге булган җир участокларында яки дәүләт милекчелеге билгеләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында куелган, законсыз урнаштырылган һәм төзелгән күчемле һәм күчемсез милекне (алда – үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объект) ачыклау һәм сүтү тәртибен билгели.

1.4. Үзбелдек белән урнаштырыган күчемле һәм күчемсез объект ул – Баулы шәһәре муниципаль милеге булган җир участокларында яки дәүләт милекчелеге билгеләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында закончалыкта каралган хокукый нигезсез урнаштырылган күчемле яки күчемсез объект.

1.5. Законсыз урнаштырылган күчемле һәм күчемсез объект ул – Баулы шәһәре муниципаль милеге булган җир участокларында яки дәүләт

милекчелеге билгеләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында урнаштыру хокукы беткән килеш урнаштырылган күчемле яки күчемсез объект.

1.6. Күчемле милек объектлары булып торалар: стационарлы булмаган сәүдә объектлары, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү (алда – сәүдә объектлары) объектлары, шул исәптән күчерелә торган корылмалар, капиталь булмаган металл гаражлар, контейнерлар, бүтән күчерелә торган конструкцияләр, механизмнар, төзелеш материаллары, коймалар һәм башка күчемле милек (алда – бүтән объектлар). Күчемсез милек булып капиталь төзелеш объектлары (гаражлар, бакча йортлары һәм башка корылмалар) тора.

1.7. Әлеге Нигезләмә таләпләре законсыз урнаштырылган яки (һәм) үзбелдек белән урнаштырылган тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларына тарала.

## 2. Үзбелдек белән урнаштырылган, законсыз урнаштырылган һәм төзелгән күчемсез һәм күчемле милек объектларын ачыклау һәм исәпкә алу

2.1. Үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектлар “Баулы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вазифаи затлары яки алар вәкаләт биргән затлар тарафыннан муниципаль контроль кысаларында, район территориясен тикшерү барышында ачыклана, шулай ук түбәндәге очракларда:

1) җирле үзидарә органнарыннан, контроль, күзәтчелек һәм хокук саклау органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан алынган мәгълүмат нигезендә;

2) объект урнаштыру барышында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган гражданнар, эшмәкәрләр, юридик затлар мөрәҗәгатьләре нигезендә;

3) массакүләм мәгълүмат чараларыннан, “Интернет” челтәреннән алынган мәгълүмат нигезендә;

4) башка мәгълүмат чыганаклары нигезендә.

2.2. Ачыкланган үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектлар турында мәгълүмат Татарстан Республикасы "Баулы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрелә.

2.3. Татарстан Республикасы "Баулы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты ачыкланган үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектларның исәбен алып бара һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында түбәндәге мәгълүматның басылуын тәэмин итә: үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектның тибы, аның урнашу урыны, ачыклануы датасы һәм аны ирекле рәвештә сүтү датасы, үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектның хуҗасы (ул ачыкланган булса).

2.4. Үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объект хуҗасы билгесез булса, вәкаләтле орган ул объектта әлеге Нигезләмәнең 2.5. пунктында каралган срокта үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектны ирекле рәвештә сүтү турында игълан элә.

2.5. Үзбелдек белән төзелгән (законсыз) күчемле милек объектын ирекле рәвештә сүтү срогы Баулы муниципаль районы рәсми сайтында һәм басма матбугатта әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында каралган мәгълүмат басылганнан соң 10 көн тәшкил итә.

2.6. Әгәр үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объект хуҗасы билгеле булса, Татарстан Республикасы "Баулы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктында каралган чаралардан тыш, үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объект хуҗасына белдерүле заказлы хат белән үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектны ирекле сүтү һәм территорияне киләчәктә файдаланырлык хәлгә китерү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә.

2.7. Үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объект хуҗасы билгесез булса яки ул аны әлеге Нигезләмәнең 2.5. пунктында каралган срокта ирекле рәвештә сүтмәсә:

– Татарстан Республикасы “Баулы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты мондый объектны мәҗбүриләп сүттерү турында муниципаль хокукый акт кабул итә (алда – күрсәтмә).

2.8. Күрсәтмә үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектны ирекле сүтү өчен билгеләнгән срок үтеп биш көн эчендә чыгарыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

- сүтелергә тиешле үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектның төре һәм урнашу урыны;

- үзбелдек белән төзелгән (законсыз) объектны сүтү срогы;

- үзбелдек белән булдырылган (законсыз) объектны (төзелеш материалларын, корылма конструкциясе элементларын һәм башкаларны) саклау урынының төгәл адресы;

- үзбелдек белән булдырылган (законсыз) объектны сүтү, күчерү һәм саклау өчен җаваплы вазифаи зат турында мәгълүмат.

2.9. Күрсәтмәләр Баулы муниципаль районы хокукый актларын рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә бастырла.

2.10. Күрсәтмә күчермәсе тиешле эчке эшләр органына җибәрелә.

2.11. Мәҗбүриләп сүттерү күрсәтмәдә билгеләнгән вакытта, ләкин ирекле сүтү өчен билгеләнгән сроктан соң 30 көннән дә соңрак түгел. Күчемсез милек объектлары өчен Россия Федерациясе Гражданлык закончалыгы 222нче статьясында каралган срок кулланыла.

2.12. Үзбелдек белән булдырылган (законсыз) объектны сүтү, күчерү, хуҗасына кайтару тәртибе, шулай ук үзбелдек белән булдырылган (законсыз) объектны сүтү, күчерү, саклау, транспортта күчерү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибе Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.